| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 31 май № 362

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 30 апрель, 289 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 30 апрель, 289 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 13 декабрь, 985 нче, 2015 ел, 20 март, 179 нчы, 2015 ел, 15 сентябрь, 677 нче, 2015 ел, 9 декабрь, 931 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт программасы
ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Дәүләт программасы исеме | «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасы (алга таба – Программа) |

| | |
|---|---|
| Программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Программаның дәүләт заказчылары | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы;<br>«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы;<br>Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе |
| Программаның максатлары | Татарстан Республикасы халкын һәркем сатып алырлык һәм сыйфатлы торак белән тәэмин итү;<br>торак фондының сыйфатын һәм энергия нәтиҗәлелеген, халыкның коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителү дәрәҗәсен, коммуналь хезмәт күрсәтүләрнең ышанычлылыгын һәм сыйфатын күтәрү |
| Программаның бурычлары | Торак сатып алганда һәм торак шартларын яхшыртканда гражданнарга ярдәм күрсәтү буенча дәүләт йөкләмәләрен һәм социаль гарантияләрне үтәү;<br>торак төзелешендә инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен шартлар тудыру, шул исәптән нәтиҗәле файдаланылмый торган федераль җирләрне әйләнешкә кертү һәм территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру өлешендә;<br>торак-коммуналь хуҗалыкның энергия нәтиҗәлелеген күтәрү;<br>коммуналь инфраструктураны киләчәктә үстерү һәм ышанычлы булуын арттыру;<br>халыкны билгеләнгән санитария-эпидемиология кагыйдәләренә туры килгән эчә торган чиста су белән тәэмин итү;<br>Татарстан Республикасы торак пунктларын төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү буенча республика программаларын |

<table>
<tr><td></td><td>тормышка ашыру юлы белән яшәү өчен уңайлы мохит шартларын булдыру;<br>архитектура, шәһәр төзү, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендә, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалыкта дәүләт сәясәтенең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен шартлар тудыру</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары</td><td>2014 - 2020 еллар.<br>I этап: 2014 - 2016 еллар;<br>II этап: 2017 - 2020 еллар</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программалар исемлеге</td><td>«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү»;<br>«2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларны торак урыннар белән тәэмин итү»;<br>«2014 – 2020 елларга территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру»;<br>«2014 – 2017 елларда гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча адреслы республика программасы чараларын тормышка ашыру»;<br>«2014 – 2020 елларда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасы чараларын тормышка ашыру»;<br>«2016 – 2020 елларга торак-коммуналь хуҗалыкта энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү»;<br>«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын су һәм җылылык белән тәэмин итү хезмәтләре тәэминатын яхшырту»;<br>«2015 – 2020 елларга социаль һәм инженер инфраструктурага бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт»;<br>«2014 – 2020 елларга архитектура, шәһәр төзү, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендә, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалыкта дәүләт сәясәтен тормышка ашыру»</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме 51 607 460,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Барлык акча</th><th rowspan="2">Татарстан Республикасы бюджеты</th><th colspan="4">Җәлеп итергә планлаштырылган акча</th></tr>
<tr><th>федераль бюджет</th><th>Дәүләт корпорациясе – Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга булышлык күрсәтү фонды</th><th>жирле бюджетлар</th><th>бюджеттан тыш чыганаклар</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>6903551,5</td><td>2292812,8</td><td>93697,7</td><td>1309906,3</td><td>1071945,0</td><td>2135189,7</td></tr>
</table>
</td></tr>
</table>

<table>
<tr>
<td></td>
<td>
<table>
<tr><td>2015</td><td>13496569,8</td><td>8268814,8</td><td>476375,4</td><td>1340147,1</td><td>1072931,0</td><td>2338301,5</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>9952786,9</td><td>5375197,1</td><td>50485,0</td><td>1096232,0</td><td>1072561,0</td><td>2358311,8</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>5804077,0</td><td>2087092,4</td><td>87487,7</td><td>350734,0</td><td>1072931,0</td><td>2205831,9</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>5129884,1</td><td>1851121,2</td><td>-</td><td>-</td><td>1072931,0</td><td>2205831,9</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>5150427,7</td><td>1871664,7</td><td>-</td><td>-</td><td>1072931,0</td><td>2205831,9</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>5170163,1</td><td>1891400,2</td><td>-</td><td>-</td><td>1072931,0</td><td>2205831,9</td></tr>
<tr><td>Бар-<br>лыгы</td><td>51607460,0</td><td>23638103,3</td><td>708045,8</td><td>4097019,4</td><td>7509161,0</td><td>15655130,6</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш
</td>
</tr>
<tr>
<td>Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td>
<td>Программа чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>2016 ел ахырына:<br>950 ятим баланы һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларны торак урыннар белән тәэмин итүгә;<br>187 яшь гаиләнең торак шартларын яхшыртуга;<br>торак фондының гомуми күләмендә искергән һәм авария хәлендәге торак фонды өлешен 1,1 процентка кадәр киметүгә;<br>2021 елга:<br>Татарстан Республикасының уртача бер кешесенә туры килә торган торак урыннарның гомуми мәйданын 27,3 метрга кадәр арттыруга;<br>Татарстан Республикасы торак фондының гомуми мәйданында барлык төр уңайлыклар белән тәэмин ителгән торак фонды мәйданы өлешен 76 процентка кадәр арттыруга;<br>күпфатирлы йортларда бер кешегә салкын суны чагыштырма тотуны 35,1 куб.метрга кадәр, бер кешегә кайнар суны 16,8 куб.метрга кадәр, җылылык энергиясен елга 1 кв.метр мәйданга 0,2 Гкал кадәр киметергә;<br>тапшырылган җылылык энергиясенең гомуми күләмендә аны тапшырганда булган югалтулар өлешен 12,6 процентка кадәр киметергә»;</td>
</tr>
</table>

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Программаның төп максатлары һәм бурычлары, программа чаралары, көтелә торган соңгы нәтиҗәләр тасвирламасы, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 ел, 17 ноябрь, 1662-б боерыгы белән расланган Россия Федерациясенең 2020 елга кадәр чорга озак вакытлы социаль-икътисадый үсеш концепциясе нигезендә халыкны һәркем сатып алырлык һәм

сыйфатлы торак белән тәэмин итү, нәтиҗәле торак-коммуналь хуҗалык һәм кеше өчен уңайлы мохит булдыру дәүләт торак сәясәтенең өстенлеге булып тора.

Программаның максатлары – Татарстан Республикасы халкын һәркем сатып алырлык һәм сыйфатлы торак белән тәэмин итү; торак фондының сыйфатын һәм энергия нәтиҗәлелеген, халыкның коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителү дәрәҗәсен, коммуналь хезмәт күрсәтүләрнең ышанычлылыгын һәм сыйфатын күтәрү.

Программаның максатларына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

торак сатып алганда һәм торак шартларын яхшыртканда гражданнарга ярдәм күрсәтү буенча дәүләт йөкләмәләрен һәм социаль гарантияләрне үтәү;

торак төзелешендә инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен шартлар тудыру, шул исәптән нәтиҗәле файдаланылмый торган федераль җирләрне әйләнешкә кертү һәм территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру өлешендә;

гражданнар яшәве өчен имин һәм уңайлы шартлар тудыру;

торак-коммуналь хуҗалыкның энергия нәтиҗәлелеген күтәрү;

коммуналь инфраструктураны киләчәктә үстерү һәм ышанычлы булуын арттыру;

халыкны билгеләнгән санитария-эпидемиология кагыйдәләренә туры килгән эчә торган чиста су белән тәэмин итү;

Татарстан Республикасы торак пунктларын төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү буенча республика программаларын тормышка ашыру юлы белән яшәү өчен уңайлы мохит шартларын булдыру;

архитектура, шәһәр төзү, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендә, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалыкта дәүләт сәясәтенең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен шартлар тудыру.

Программа чараларын тормышка ашыру 2020 елга түбәндәгеләргә ирешергә ярдәм итәчәк:

Татарстан Республикасы халкы яшәсен һәм тереклек эшчәнлеге алып барсын өчен имин һәм уңайлы мохит тудыру;

республикада демографик хәлне яхшырту, җәмгыятьтә социаль киеренкелекне киметү өчен шартлар тудыру;

халыкның коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен күтәрү;

кулланучыларга хезмәт күрсәтүнең сыйфатын, ышанычлылыгын һәм экологик иминлеген арттыру;

торак фонды һәм коммуналь инфраструктураның уртача тузу дәрәҗәсен киметү.

Программа 2014 – 2020 елларда тормышка ашырылачак.

Тормышка ашыруның ике этабы күздә тотыла:

I этап: 2014 – 2016 еллар;

II этап: 2017 – 2020 еллар.

I этапның төп нәтиҗәләре (үз вакытында финанслар белән тәэмин иткәндә һәм чараларны план нигезендә үтәгәндә):

950 ятим бала һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затлар торак урыннар белән тәэмин ителәчәк;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы кысаларында 187 яшь гаиләнең торак шартлары яхшыртылачак;

торак фондының гомуми күләмендә искергән һәм авария хәлендәге торак фонды өлешен 1,1 процентка кадәр кимеячәк.

II этапның төп нәтиҗәләре:

Татарстан Республикасының уртача бер кешесенә туры килә торган торак урыннарның гомуми мәйданы 27,3 метрга кадәр арттырыла;

Татарстан Республикасы торак фондының гомуми мәйданында барлык төр уңайлыклар белән тәэмин ителгән торак фонды мәйданы өлеше 76 процентка кадәр арттырыла;

күпфатирлы йортларда бер кешегә салкын суны чагыштырма тоту 35,1 куб.метрга кадәр, бер кешегә кайнар су 16,8 куб.метрга кадәр, җылылык энергиясе елга 1 кв.метр мәйданга  0,2 Гкал кадәр киметелә;

тапшырылган җылылык энергиясенең гомуми күләмендә аны тапшырганда булган югалтулар өлеше 12,6 процентка кадәр киметелә.

Программаның максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре исемлеге, планлаштырылган мәгънәләрне тормышка ашыру еллары буенча бүленеп, әлеге Программага кушымтада китерелгән.

Күрсәткечләр исемлеге ачык характерда һәм күрсәткечнең информативлыгы югалган, дәүләт сәясәтенең өстенлекләре алышынган очракта тәгаенләү мөмкинлеген күздә тота.

Программаның төп максатлары һәм бурычлары Программаның тиешле ярдәмче программалары кысаларында каралган чаралар комплексын тормышка ашырмыйча ирешелә алмый.

2.1. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы

Әлеге ярдәмче программа «Россия гражданнарына – һәркем сатып алырлык һәм уңайлы торак» өстенлекле илкүләм проект чараларын киләчәктә Татарстан Республикасында тормышка ашыру максатларында кабул ителде, аның төп коралы булып «Торак» федераль максатчан программасы тора. «Торак» федераль максатчан программасы составына «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы кертелгән, анда Россия Федерациясе субъектлары катнашу өчен яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итүнең тиешле төбәк программасы булу һәм бергә финанслау буенча йөкләмәләр шарт булып тора.

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасының максаты – билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә торак мәсьәләләрен хәл итүдә өстәмә дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү.

Ярдәмче программаның төп бурычы – яшь гаиләләргә (программада катнашучыларга) экономик класслы торак сатып алуга яки экономик класслы хосусый торак йорт төзүгә социаль түләүләр бирү;  яшь гаиләләргә үз акчаларын,

банкларның һәм башка оешмаларның, шул исәптән торак сатып алу яки хосусый торак төзелеше өчен ипотека торак кредитлары һәм заемнар бирүче, өстәмә финанс чараларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру.

Ярдәмче программа чаралары системасын тормышка ашыру түбәндәге юнәлешләрдә башкарыла:

ярдәмче программаны тормышка ашыруны норматив-хокукый һәм методологик тәэмин итү;

ярдәмче программаны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү;

ярдәмче программаны тормышка ашыруны оештыру ягыннан тәэмин итү.

2.2. «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларны торак урыннар белән тәэмин итү» ярдәмче программасы

«Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны социаль яклау буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы белән ятим балаларның һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларның (алга таба ятим балалар) торак урыннарга хокукларына өстәмә гарантияләр билгеләнде, алар нигезендә социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарның наемчылары яки социаль наем шартнамәләре буенча торак урынның наемчысы гаиләсе әгъзалары яисә торак урыннарның милекчеләре булмаган ятим балаларга, шулай ук социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарның наемчылары яки социаль наем шартнамәләре буенча торак урынның наемчысы гаиләсе әгъзалары яисә торак урыннарның милекчеләре булган ятим балаларга аларның элек биләгән торак урыннарда яшәүләре мөмкин түгел дип танылган очракта территориясендә әлеге затларның яшәү урыннары урнашкан Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы тарафыннан, бу Россия Федерациясе субъекты законнарында билгеләнгән тәртиптә бер тапкыр махсуслашкан торак урыннары наемы шартнамәләре буенча махсуслашкан торак фондының уңайлаштырылган торак урыннары бирелә.

Ярдәмче программаның максаты – ятим балалар арасындагы затларны торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү.

Ярдәмче программаның бурычлары түбәндәгеләр:

торак урыннар белән тәэмин ителергә тиеш ятим балаларның исәбен алу;

ятим балалар өчен Татарстан Республикасы махсуслашкан торак фондын булдыру;

Татарстан Республикасы махсуслашкан торак фондының торак урыннарын ятим балаларга бирү.

Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2017 ел ахырына 1 268 ятим баланы торак урын белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

2.3. «2014 – 2020 елларга территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру»

Ярдәмче программаны эшләү өчен нигезләр: Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып алырлык һәм

уңайлы торак белән тәэмин итү һәм торак-коммуналь хезмәтләр сыйфатын күтәрү чаралары турында» 2012 ел, 7 май, 600 нче Указы; «Торак төзелешен үстерүгә ярдәм күрсәтү турында» 2008 елның 24 июлендәге Федераль закон; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 ел, 17 декабрь, 1050 нче карары белән расланган «Торак» федераль максатчан программасының «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларын стимуллаштыру» ярдәмче программасы.

Ярдәмче программаның төп максаты – территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру өлешендә торак төзелешендә инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен шартлар булдыру.

Ярдәмче программа кысаларында торак төзелешен үстерү программаларын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр алу буенча чаралар тормышка ашырылачак, алар түбәндәгеләргә файдаланыла ала:

экономик класслы торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрен инженер инфрастуктурасы белән тәэмин итү максатларында заемчылар тарафыннан россия кредит оешмаларында алынган кредитлар буенча процентлар түләүгә чыгымнарны (чыгымнар өлешен) кире кайтару;

экономик класслы торак төзелешен күздә тота торган территорияләрне комплекслы үстерү буенча проектларны тормышка ашыру кысаларында социаль инфраструктура объектларын төзү (төзекләндерү);

массакүләм аз катлы һәм күпфатирлы экономик класслы торак төзелгән микрорайоннарда автомобиль юлларын төзү(төзекләндерү).

Федераль милектәге нәтиҗәсез файдаланыла торган җир кишәрлекләрен, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү буенча чаралар кысаларында мондый җир кишәрлекләрен билгеләү буенча эш, бу җир кишәрлекләрен киләчәктә файдалануны карап тикшерү күздә тотыла.

2.4. «2014 – 2017 елларда гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча адреслы республика программасы чараларын тормышка ашыру» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаны эшләү өчен нигез: «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга булышлык күрсәтү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон.

Ярдәмче программаның төп максаты – билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган һәм җирле үзидарә органы «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга булышлык күрсәтү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән Дәүләт корпорациясе – Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга булышлык күрсәтү фонды исәбеннән финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне тәэмин иткән шартларда милекчеләре гражданнарны күчерүнең төбәк программасында катнашырга әзер булган авария хәлендәге күпфатирлы йортлардан гражданнарны күчерүне финанслау һәм оештырылган тәэмин итү.

Ярдәмче программаның бурычлары – авария хәлендә һәм яшәү өчен яраксыз дип танылган торак фондыннан гражданнарны күчерү; эксплуатацияләү процессында физик тузу белән бәйле авария хәлендә дип танылган һәм җимерелергә яки төзекләндерелергә тиешле күпфатирлы йортларны җимерү яки төзекләндерү; авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарга күчү өчен шартлар тудыру.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча 2012 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендә дип танылган торак фонды тулысынча бетереләчәк.

2.5. «2014 – 2020 елларда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасы чараларын тормышка ашыру» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаны эшләү өчен нигезләр: Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь төзәтү үткәрүне оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

Ярдәмче программаның төп максаты – гражданнарга яшәү өчен имин һәм уңайлы шартлар тудыру, торак фонды сыйфатын саклау, торгызу һәм күтәрү, Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларның техник торышын яхшырту.

Ярдәмче программаның бурычы – күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь төзәтүне үз вакытында үткәрүне нәтиҗәле планлаштыру һәм оештыру, чыдам материаллар һәм ресурслар саклаучы технологияләр кулланып капиталь төзәтү үткәргәндә нәтиҗәле техник карарлардан һәм комплекслылыктан файдалану.

Торак фондын Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китерү (шул исәптән халыкның санитария-эпидемиология иминлеге, техник җайга салу, кулланучылар хокукларын яклау турында) ярдәмче программаны үтәү нәтиҗәсе булачак.

2.6. «2016 – 2020 елларга торак-коммуналь хуҗалыкта энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаның максаты – торак-коммуналь хуҗалыкта энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрү.

Ярдәмче программаның бурычлары:

торак фондта энергетика ресурслары һәм су куллануны киметү;

энергетика ресурслары һәм су җитештергәндә (тапшырганда) энергия саклауны тәэмин итү.

Ярдәмче программа чаралары түбәндәгеләргә ярдәм итәчәк:

Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгында энергетика нәтиҗәлелеген күтәрүгә;

энергетика ресурсларын һәм суны куллану өчен чыгымнар кимүгә.

2.7. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын су һәм җылылык белән тәэмин итү хезмәтләре тәэминатын яхшырту» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаның максатлары:

халыкны билгеләнгән санитария-эпидемиология кагыйдәләренә туры килгән эчә торган чиста су белән тәэмин итү;

су белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгына һәм ресурс нәтиҗәлелегенә ирешү;

торак-коммуналь комплекс оешмаларының җылылык белән тәэмин итү системалары эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү.

Ярдәмче программаның бурычлары:

халыкның үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм су агу хезмәтләре белән тәэмин ителешен арттыру;

заманча технологияләр кулланып су белән тәэмин итү системаларын үстерү;

суны рациональ куллануны һәм эчә торган суны югалту күләмен киметүне тәэмин итү;

авыл халкына җылылык белән тәэмин итү һәм кайнар су белән тәэмин итү буенча сыйфатлы коммуналь хезмәтләр күрсәтү;

авыл халкын аварияләрсез, өзлексез җылылык белән тәэмин итү һәм кайнар су белән тәэмин итүне булдыру.

Ярдәмче программа чаралары түбәндәгеләргә ярдәм итәчәк:

гражданнарның тереклек дәрәҗәсен күтәрүгә һәм яшәүләрен уңайлы итәргә;

авыл халкының коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен күтәрүгә;

кулланучылар өчен коммуналь хезмәт күрсәтүләрнең һәркем файдалана алырлык булуын сакларга;

кулланучыларга хезмәт күрсәтүнең сыйфатын, ышанычлылыгын һәм экологик иминлеген күтәрүгә;

җылылык белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүне киметергә;

табигый газдан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрергә.

2.8. «2015 – 2020 елларга социаль һәм инженер инфраструктурага бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаның максатлары:

яшәү шартларының уңайлылыгын һәм халыкның коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителү дәрәҗәсен күтәрү;

коммуналь системаларның ышанычлылыгына һәм ресурслары нәтиҗәлелегенә ирешү;

билгеләнгән санитария-эпидемиология таләпләренә туры килә торган эчә торган су белән халыкны тәэмин итү.

Ярдәмче программаның бурычлары:

заманча технологияләрне гамәлгә кертеп коммуналь инфрастуктураны алга таба үстерү;

авыл халкын аварияләрсез, өзлексез җылылык белән тәэмин итү һәм су белән тәэмин итү чыганакларын булдыру;

Татарстан Республикасы торак пунктларын төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү буенча республика программаларын тормышка ашыру.

Ярдәмче программа чаралары түбәндәгеләргә ярдәм итәчәк:

Татарстан Республикасы халкының яшәве һәм тереклек эшчәнлеге өчен уңайлы мохит булдырырга;

халыкның коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен күтәрергә;

Татарстан Республикасы торак пунктларын төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрергә.

Ярдәмче программаны тормышка ашыруның экологик нәтиҗәлелеге төп җиһазларны төзекләндерү һәм яңарту, челтәрләр һәм җиһазларның ышанычлылыгын күтәрү исәбенә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү белән билгеләнә.

2.9. «2014 – 2020 елларга архитектура, шәһәр төзү, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендә, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалыкта дәүләт сәясәтен тормышка ашыру» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаның максаты – архитектура, шәһәр төзү, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендә, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалыкта дәүләт сәясәтенең нәтиҗәлелеген күтәрү юлы белән Татарстан Республикасының тотрыклы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү.

Ярдәмче программаның бурычлары – территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналарга бүлү нигезендә Татарстан Республикасы үсешен тәэмин итү, граждан һәм сәнәгать төзелеше үсеше өчен шартлар тудыру, гражданнарның яшәү стандартлары һәм күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын тәэмин итү.

Ярдәмче программа түбәндәге чараларны үтәүне күздә тота:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының архитектура, шәһәр төзү, граждан һәм сәнәгать төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә гомумпрограмма эшчәнлеген;

5 һәм күберәк балалары булган, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүне;

республика дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыруны;

коммуналь хуҗалык өлкәсендә башка чараларны (авария-техник запасны тулыландыру, мәгълүмат-пропаганда эшчәнлеге, «Татарстан Республикасының иң төзек торак пункты» конкурсын үткәрү һәм башкалар).»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү фаразы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет, Дәүләт корпорациясе – Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга булышлык күрсәтү фонды, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2014 – 2020 елларда Программаны финанслауның фаразлана торган гомуми күләме 51 607 460,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Татарстан Республикасы бюджеты | Җәлеп итергә планлаштырылган акча | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | федераль бюджет | Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга булышлык күрсәтү фонды | җирле бюджетлар | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2014 | 6903551,5 | 2292812,8 | 93697,7 | 1309906,3 | 1071945,0 | 2135189,7 |
| 2015 | 13496569,8 | 8268814,8 | 476375,4 | 1340147,1 | 1072931,0 | 2338301,5 |
| 2016 | 9952786,9 | 5375197,1 | 50485,0 | 1096232,0 | 1072561,0 | 2358311,8 |
| 2017 | 5804077,0 | 2087092,4 | 87487,7 | 350734,0 | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2018 | 5129884,1 | 1851121,2 | - | - | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2019 | 5150427,7 | 1871664,7 | - | - | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2020 | 5170163,1 | 1891400,2 | - | - | 1072931,0 | 2205831,9 |
| Барысы | 51607460,0 | 23638103,3 | 708045,8 | 4097019,4 | 7509161,0 | 15655130,6 |

Программа юнәлешләре буенча финанслау күләмнәре, тиешле бюджетлар мөмкинлекләреннән чыгып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Барлык чыганаклар исәбеннән Программаны ресурслар белән тәэмин итү һәм Программаны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының фараз кыйммәте бу Программага теркәлгән кушымтада китерелә.»;

Программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә);

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программа-ны финанс-лау күләм-нәре һәм чыганакла-ры</td>
<td>Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 925 249,3 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Барлык акча</th><th colspan="4">Шул исәптән акча</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты</th><th>җәлеп итергә планлаштырылган федераль бюджет</th><th>җәлеп итергә планлаштырылган җирле бюджетлар</th><th>җәлеп итергә планлаштырылган бюджеттан тыш чыганаклар</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>139291,29</td><td>50000,0</td><td>10291,29</td><td>-</td><td>79000,0</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>140958,04</td><td>50000,0</td><td>11958,04</td><td>-</td><td>79000,0</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>129000,0</td><td>50000,0</td><td>*</td><td>-</td><td>79000,0</td></tr>
